**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы карары (өченче чакырылыш)**

Азнакай шәһәре № 89-24 2018 елның "30" мартыннан

Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Советы **карары:**

1. Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы карары белән расланган бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә, 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү эшләнгән) акчаларны алу чыганаклары турында

белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.М. Нәгыймов өстенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин